| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.01.2020 п.г.т.Алексеевское № 2

**«Алкоголь продукциясенең законсыз әйләнешен ачыклау һәм булдырмау буенча ведомствоара комиссия төзү турында» 2018 елның 07 декабрендәге 434 номерлы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә һәм аннан читтә югары сыйфатлы алкоголь продукциясен җитештерү һәм сату күләмнәрен арттыру чаралары турында» 2004 елның 16 гыйнварындагы 10 номерлы карары нигезендә һәм югары сыйфатлы алкоголь продукциясен җитештерү һәм сату күләмнәрен арттыру, аның ассортиментын киңәйтү, шулай ук эчке кулланучылар базарыннан ялган алкоголь продукциясен этеп чыгару максатларында

**карар кылам**:

1. Алкоголь продукциясенең законсыз әйләнешен ачыклау һәм кисәтү буенча ведомствоара комиссия составына (Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 07 декабрендәге 434 номерлы карарына 1 нче кушымта) түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр кертергә:

- «Яковлев В.А. – Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы Алексеевск районындагы бүлеге башлыгы (килешү буенча), комиссия әгъзасы» сүзләрен «Юнысов Р.Р. – Россия Эчке эшләр министрлыгының Алексеевск районы буенча бүлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы (килештерү буенча), комиссия әгъзасы» сүзләренә алмаштырырга;
- «Фәхретдинов И.А. – «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча), комиссия әгъзасы» сүзләрен «Фассахова А.Р. – «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча), комиссия әгъзасы» сүзләренә алмаштырырга;

- Гыйләҗев Д.А.- «Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы, комиссия әгъзасы» сүзләрен «Сөләйманов Р.Б. - «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы, комиссия әгъзасы» сүзләренә алмаштырырга;

- «шәһәр һәм авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча), комиссия әгъзалары» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К.Кадыйров**